# Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы

## КАРАРЫ

**№ 223** **20.05.2020 ел.**

**«2019 елда Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында»**

Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 ел өчен Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 5619,0 мең сум, чыгымнар буенча 4772,4 мең сум, керемнәрне чыгымнардан 846,6 мең сумга арттырып, һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1.1. 2019 ел өчен бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;

1.2. 2019 ел өчен бюджет керемнәре буенча әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә;

1.3. тармак структурасы буенча бюджет чыгымнарын 4нче кушымта нигезендә һәм чыгымнарның функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча 2019 ел өчен бюджет чыгымнарын бүлүне әлеге карарга 3нче кушымта нигезендә расларга.

2. Карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Александр Бистәсе**
**авыл җирлеге башлыгы** **Л.Г. Варганова**